**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28 декабрь, 2022 ел** **№ 253**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 20 пункты, 3 өлеше нигезендә, 2022 елның 24 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге» муниипаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча 2022 елның 24 декабрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелгән Генераль планын расларга.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планына материаллар белән https://fgis-tp.ru сайтында 9262247902020304202210241 УИН буенча танышырга мөмкин.